**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Большенуркеевского сельского**
**поселения Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының**
**Зур Нөркәй авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17 июнь 2020 ел

КАРАР
№ 6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2015 елның 24 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законга, «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Аквакультура (балык үрчетү) турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 502-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга, Сарман муниципаль берәмлегенең «Зур Нөркәй авыл җирлеге» Уставына нигезләнеп,карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2015 елның 24 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Зур Нөркәй авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М.Гайсин